ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.05.2024 г. № 457

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 ноябрендәге 1258 номерлы карары белән расланган 2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплексллы программага үзгәрешләр кертү турында

Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе утырышының 2023 елның 15 декабрендә узган 4номерлы утырышы тәкъдимнәре нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 30.11.2021 ел № 1258 карары белән расланган 2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплексы программага (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплексы программа чаралары буенча максатлар, бурычлар һәм финанслау» бүлегендәге программаның 1нче кушымтасында 3.10 пунктын өстәргә. (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 6 маендагы 457 номерлы карарына 1 нче кушымта

## 2022-2025 елларга Нурлат муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программа чаралары буенча максатлар, бурычлар һәм финанслау

| Төп чараларның атамалары | Гамәлгә куючылар | Төп чараларны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү күрсәткечләре, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның кыйммәтләре | | | | | Җирле бюджет акчалары хисабына финанслау, (млн. сум.) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 (база) | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 7 | 8 | 9 | 10 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| **Задача 3.** Хөкем ителгәннәрне иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итүгә әзерләүне оештыру | | | | | | | | | | | | |
| 3.10. Иректән мәхрүм итү, мәҗбүри эшләр рәвешендә җәзаны үтәүче учреждениеләрдән азат ителгәннәрне һәм җәмгыятьтән изоляцияләү белән бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгәннәрне ресоциализацияләү, социаль адаптацияләү һәм социаль | ФКУ УИИ УФСИН России по РТ (килешү буенча), ЦЗН (килешү буенча), ОСЗ (килешү буенча), | 2024-2025 | | | | | | | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| реабилитацияләү буенча чаралар үткәрүне тәэмин итәргә (социаль элемтәләрне торгызу, социаль һәм Хокукый мәсьәләләр буенча консультация бирү, документларны алуда һәм торгызуда, эшкә урнашуда, һөнәри белем бирүдә, тиешле социаль хезмәтләр, түләүләр, пособиеләр, башка ярдәм алуда). | | | | | | | | | | | | |